**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
31.10.2019

**КАРАР**
№ 750

# 2019 нчы елның III кварталына һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

“Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында”гы 2015нче елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү Методикасы нигезендә, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты **Карар бирә:**

1. Гражданнарны 2019 елның III кварталына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында, гражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләренең бәясен билгеләргә.

Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чиге:

1.1.1. Бер үзе генә яшәүче гражданина – 1 655 445 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаиләгә – 2 106 930 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаиләгә – 2 708 910 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаиләгә – 3 611 880 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаиләгә – 4 514 850 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаиләгә – 5 417 820 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаиләгә – 6 320 790 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына уртача туры килә торган айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. Бер үзе генә яшәүче гражданина – 12 087,76 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаиләгә – 7 692,21 сум;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кеше булган гаилә өчен - 6 593,32 сум.

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**